Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № X-13**

Балык Бистәсе штп. 2016 елның 23 апреле

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы авыл җирлекләре территорияләрендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру турында

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы авыл җирлекләре территорияләрендә муниципаль торак контролен оештыру һәм гамәлгә ашыру максатларында, Россия Федерациясе Торак кодексының 20 маддәсе, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 маддәсендәге 1 өлешенең 6 пункты, 3,4 өлешләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 15 маддәсендәге 1 өлешенең 6 пункты, 5 өлеше, “Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында” 2011 елның 10 октябрендәге 72-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы авыл җирлекләре территорияләрендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру турында кушымтада бирелгән Нигезләмәне расларга.

2.Авыл җирлекләре территорияләрендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыручы орган итеп Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетын билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетына:

2.1. әлеге карарны гамәлгә ашыру максатларында муниципаль хокукый актлар кабул итәргә;

2.2. муниципаль торак контролен гамәлгә ашырганда билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе белән үзара хезмәттәшлекне тәэмин итәргә.

3. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны транспорт, төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык  Бистәсе муниципаль
район Советы рәисе                                                                                    И.Г.Вәлиев

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Советының 2016 елның 23 апрелендәге
X-13 номерлы карары белән
расланды

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы авыл җирлекләре территорияләрендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру турында Нигезләмә**

## 1.Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә Россия Федерациясе Торак кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында»2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон, «Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында» 2011 елның 10 октябрендәге 72-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә эшләнгән.

1.2. Муниципаль торак контроле – Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы авыл җирлекләре территорияләрендә юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр һәм гражданнар тарафыннан муниципаль торак фондына карата торак мөнәсәбәтләре өлкәсендә федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында, шулай ук муниципаль хокукый актларда билгеләнгән мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен тикшерүне оештыруга һәм уздыруга вәкаләтле җирле үзидарә органнары эшчәнлеге (алга таба - мәҗбүри таләпләр).

1.3.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы авыл җирлекләре территорияләрендә муниципаль торак контроле Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан гамәлгә ашырыла.

1.4.Муниципаль торак контроле органының вазыйфаи затлары муниципаль торак инспекторлары булып тора.

## 2. Муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру рәвешләре

2.1. Муниципаль торак контроле “Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында” 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тәртиптә һәм үтәлеп, планлы һәм планнан тыш тикшерүләрне оештыру һәм үткәрү үзенчәлекләрен исәпкә алып, Россия Федерациясе Торак кодексының 20 маддәсендәге 4.1 һәм 4.2 өлешләрендә билгеләнгән процедураларны үтәп гамәлгә ашырыла.

2.2. Планлы тикшерүләр Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе раслаган тикшерүләрнең еллык планы нигезендә уздырыла.

2.3. Юридик затларга (аларның филиаллары, вәкиллекләре, аерымланган структур бүлекчәләре) һәм индивидуаль эшкуарларга планлы тикшерүләр үткәрүнең еллык планнарында түбәндәге мәгълүматлар күрсәтелә:

1) эшчәнлекләре планлы тикшерелергә тиешле юридик затларның (аларның филиаллары, структур бүлекчәләре вәкиллекләре) исем-аталышлары, шәхси эшмәкәрләрнең фамилияләре, исемнәре, атасының исемнәре, юридик затларның (аларның филиаллары, вәкиллекләре, аерым структур бүлекчәләр) урнашу урыннары яки хосусый эшмәкәрләр эшчәнлеген факттагы гамәлгә ашыру урыннары;

2) һәрбер планлаштырылган тикшерүне үткәрүнең максаты һәм нигезе;

3) һәр планлаштырылган тикшерүне үткәрү датасы һәм вакыты;

4) конкрет планлы тикшерүне гамәлгә ашыручы муниципаль контроль органының аталыш-исеме. Планлы тикшерүне үткәргәндә дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары, муниципаль контроль органнары бергәләп мондый тикшерүдә катнашучы барлык органнарның аталышлары күрсәтелә.

2.4. Әлеге Нигезләмәнең 2 бүлегендә каралган тикшерүләр Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең тикшерү уздыру турындагы боерыгы (күрсәтмәсе) нигезендә гамәлгә ашырыла.

2.5. Әлеге Нигезләмәнең 2 бүлегендә каралган тикшерүләрне уздыру тәртибе Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы авыл җирлекләре территорияләрендә муниципаль торак контролен үткәрүне җайга сала торган, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән раслана торган административ регламент нигезендә гамәлгә ашырыла.

2.6. Юридик затларны һәм шәхси эшмәкәрләрне тикшерү нәтиҗәләре буенча «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында»2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә законнарның үтәлешен тикшерү акты рәсмиләштерелә.

2.7. Административ хокук бозу составы булу яки мәҗбүри таләпләрне бозу турында таныклаучы билгеләр ачыкланган очракта, муниципаль торак инспекторлары Россия Федерациясе законнарында каралган вәкаләтләр чикләрендә бурычлы:

- юридик затка, хосусый эшмәкәргә ачыкланган бозуларны бетерү срокларын күрсәтеп бетерү һәм (яки) кешеләрнең гомеренә, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләргә) зыян китермәү буенча чаралар үткәрү, дәүләтнең иминлеге, физик һәм юридик затларның мөлкәте, дәүләт яисә муниципаль мөлкәте, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгуны кисәтү, шулай ук федераль законнарда каралган башка чаралар барлыкка килүне кисәтү турында күрсәтмә бирергә;

- ачыкланган хокук бозуларны бетерүне контрольдә тоту, аларны кисәтү, гражданнарның гомеренә, сәламәтлегенә зыян килү ихтималын булдырмау, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарих һәм мәдәният һәйкәлләренә), дәүләтнең иминлеген тәэмин итү, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгуны кисәтү чараларын, шулай ук ачыкланган хокук бозуларга юл куйган затларны җаваплылыкка тарту чараларын күрергә;

- административ хокук бозулар турында эшләр кузгату, җинаять билгеләре буенча җинаять эшләрен хәл итү өчен мәҗбүри таләпләрне бозуга бәйле материалларны вәкаләтле органнарга кичекмәстән җибәрергә.

Күрсәтмә күрсәтмәне биргән вазыйфаи затның фамилиясен, исемен, атасының исемен, юридик затның исемен, шулай ук физик затның фамилиясен, исемен, атасының исемен, күрсәтмә адресатын, конкрет таләпне (таләпләр исемлеген) күрсәтергә тиеш, адресатны, норматив актларга сылтамаларны, хокук бозуны бетерү срогын һәм күрсәтмә бирү датасын чагылдырырга тиеш.

Күрсәтмәгә адресат кул куярга тиеш (юридик зат өчен - аның законлы вәкиле). Күрсәтмәне имзалаудан баш тартканда, анда бу хакта тиешле билге куела һәм ул почта адресатына тапшыру турындагы белдерү белән җибәрелә. Берничә бозу очрагы ачыкланган очракта, аларны бетерү эш күләмнәренең аермасын һәм аларны башкару вакытын күздә тота, вәкаләтле вазыйфаи зат күрсәтелгән һәр хокук бозу буенча берничә күрсәтмә бирә.

2.8. Әлеге Нигезләмәнең 2.7 пунктында күрсәтелгән күрсәтмәләрне вакытында үтәмәгәндә гаепле затларны административ җаваплылыкка тарту буенча билгеләнгән тәртиптә чаралар күрелә.

2.9. Җитәкче, бүтән вазыйфаи зат яки юридик затның вәкаләтле вәкиле, шәхси эшмәкәр, шулай ук граждан Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы башкарма комитеты вазыйфаи затларының Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә административ һәм (яисә) суд тәртибендә тикшерү уздырганда юридик затның, индивидуаль эшкуарның яки гражданның хокукларын бозуга китергән гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять бирергә хокуклы.

## 3. Муниципаль торак контроле органнары, муниципаль торак контролен гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлар вәкаләтләре

3.1. Тикшерүләр уздырганда муниципаль контроль органы вазыйфаи затларының хокуклары һәм бурычлары Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының карары белән раслана торган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы авыл җирлекләре территорияләрендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыруның административ регламентында беркетелә.